| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тармакара кулланучылар советы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тармакара кулланучылар советы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тармакара кулланучылар советы турында» 2014 елның 28 февралендәге ПУ-234 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 14 мартындагы ПУ-286 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «Табигый монополияләр субъектлары» сүзләреннән соң «, табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеген җайга салуны башкаручы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тармакара кулланучылар советы турында нигезләмәдә:

10 пунктның сигезенче абзацындагы «килештерү комиссиясе һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 пунктта «җаваплы секретарь» сүзләрен «Совет рәисе урынбасары – җаваплы секретарь» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Совет рәисе урынбасары – Советның җаваплы секретаре:»;

түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Совет рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара;»;

икенче – алтынчы абзацларны тиешенчә өченче – җиденче абзацлар дип санарга;

36 пунктта «килештерү комиссиясе һәм» һәм «Килештерү комиссиясе һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

37 пункттагы, 38 пунктның икенче һәм бишенче абзацларындагы «Килештерү комиссиясе һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

39 пункттагы «Килештерү комиссиясе һәм» һәм «Килештерү комиссиясе яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Табигый монополияләр субъектлары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тармакара кулланучылар советы составында (алга таба – Совет):

Совет составыннан Н.М. Атласовны, С.Н. Гущинны, А.Н. Подоваловны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Афанасьев Михаил Павловичны – «Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгын (килешү буенча);

Кудряшов Андрей Витальевичны – Россия Либерал-демократлар партиясенең Татарстан төбәк бүлекчәсе идеология буенча координаторы урынбасарын (килешү буенча);

Фазылов Ринат Рафаэль улын – «РОССИЯ ЯКЛЫ» ХАЛЫК ФРОНТЫ» гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлекчәсе башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

И.М. Егоровның – «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Н.Г. Мәһдиевның – «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча)»;

А.М. Пахомовның – «Татарстан Республикасы Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) генераль директоры, Совет рәисе (килешү буенча);

Т.Р. Халиковның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча)», аны Совет рәисенең урынбасары – Советның җаваплы секретаре итеп расларга;

Л.Р. Шәриповның – «СтройМаш» төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 21 апрель
№ ПУ-324